# БЕЛДЕРҮ

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктының 15 пунктчасы һәм 39.18 статьясы нигезендә, Кукмара муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы түбәндәге характеристикалы җир кишәрлеген 20 елга арендага бирү турында хәбәр итә:

Кадастр номеры 16:23:040302:454, мәйданы 2438 кв.м, җир категориясе: «торак пунктлар җирләре», рөхсәт ителгән файдалану төре: «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» (Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрындагы мәгълүматлар нигезендә), кишәрлекнең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Ошторма-Юмья авыл җирлеге, Иске Юмья авылы, Үзәк урам, 44а.

Җир кишәрлегенә карата хокуклар чикләнә (күчемсез милеккә чикләнгән хокук). Мондый чикләүләр (чикләнгән хокук) әлеге хәбәргә кушымта итеп бирелгән Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан җир кишәрлегенә карата өземтәдә күрсәтелгән.

Югарыда күрсәтелгән җир кишәрлеген арендага алырга кызыксынучы гражданнар аукционда катнашу нияте турында әлеге хәбәр басылып чыкканнан соң 30 көн эчендә язма рәвештә гариза (алга таба – гаризалар) бирергә хокуклы. Гаризаны гариза бирүче (ышанычлы зат) эш көннәрендә (дүшәмбе – җомга, эшләми торган бәйрәм көннәреннән, эшләми торган көннәр дип игълан ителгән көннәрдән, ял көннәре күчерелгән көннәрдән тыш) 8.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр (12.00 сәгатьтән сәгать 13.00 гә кадәр – төшке аш өчен тәнәфес белән) Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Кукмара шәһәре, Ленин ур., 15 йорт, 101 нче бүлмәгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә тапшыра ала.

Гаризаларны кабул итү тәмамлану датасы – 2024 елның 09 гыйнвары, 15 сәгать 00 минут.